ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 декабрь 2024ел № 8037

Башкарма комитетның 2022 елның 11 октябрендәге 5459 номерлы Карары белән расланган юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының дәүләт хезмәтләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләренә туры китерү план-графигын раслау хакында» 2022 елның 5 февралендәге 89 номерлы Карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р   Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2022 елның 11 октябрендәге 5459 номерлы Карары белән (Башкарма комитетның 2023 елның 6 апрелендәге 2734 номерлы, 2023 елның 12 маендагы 3872 номерлы Карарлары редакциясендә) расланган юл билгеләрендә индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләрен урнаштыруны килештерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3.2 пунктның 2 пунктчасында «интерактив формада» сүзләреннән соң «Бердәм порталның,» сүзләрен өстәргә;

2) 2.4.1 пунктка «(гариза кергән көннән башлап).» сүзләрен өстәргә;

3) 2.5.1 пунктның 1 пунктчасында «Россия Федерациясе законы» сүзләреннән соң «(Бердәм портал, Республика порталы аша мөрәҗәгать иткән очракта таләп ителми);» сүзләрен өстәргә;

4) 2.5.1 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5 пунктча өстәргә;

«5) юл билгеләре милекчеләре тарафыннан килешүләр (урамнарны яктырту баганаларына һәм мачталарына һәм электр җир өсте транспортының контакт

челтәрләренең беркеткечләре урнаштырылганнарына индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләрен (мәгълүмат модуле белән) урнаштырганда).»;

5) 2.5.2 пунктның 2 пунктчасында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

6) 2.8.1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.8.1. Хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр исемлеге:

1) индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләренең (мәгълүмат модуле белән) тышкы күренешен, язуларны үзгәртү;

2) индивидуаль проектлауның мәгълүмат билгеләре (мәгълүмати модуль белән) аларны урнаштыру буенча техник шартларга туры килмәү.»;

7) 2.8.2 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 6-8 пунктчалар өстәргә:

«6) юл билгесендә күрсәтелгән юнәлеш һәм объектка кадәр ераклык чынбарлыкка туры килмәү;

7) юл хәрәкәте иминлеге комиссиясенең гаризада (4 нче кушымта) күрсәтелгән участокта индивидуаль проектлауның мәгълүмати билгеләрен (мәгълүмат модуле белән) урнаштыруның максатчан булмавы турында карары булу;

8) урнаштыру өчен тәкъдим ителә торган юл хәрәкәтен оештыруның техник чарасы реклама билгеләренә ия.»;

8) 2.13.2 пунктта «кабинетында» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

9) 2.15.2 пунктның тугызынчы абзацында «файдаланып» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

10) 2.16.1 пунктның 2 пунктчасында «файдаланып» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

11) 2.16.1 пунктның 6 пунктчасында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

12) 2.16.2 пунктта «гаризаның» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

13) 2.16.4 пунктның беренче абзацында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

14) 2.16.4 пунктның дүртенче абзацында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

15) 3.5.3.2 пунктның беренче абзацында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә;

16) 3.6.1 пунктның бишенче абзацында «аша» сүзеннән соң «Бердәм портал,» сүзләрен өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов